| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**16.11.2023** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№3589** |

2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^2$ статьясындагы 4 пункты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге карарга кушымтада бирелгәнчә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2022 елның 11 декабрендәге 3112 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар, 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеттан башлап, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә Интернет челтәредә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының 2023 елның
16 ноябрендәге 3589 номерлы
карарына кушымта

## Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге

| Башлык коды | Чыганакларның төркем, төркемчә, статья һәм төрләре коды | Атамасы |
|---|---|---|
| 802 | | Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты |
| 802 | 01 05 02 01 13 0000 510 | Шәһәр җирлекләре бюджетларының башка калган акча өлешләрен арттыру |
| 802 | 01 05 02 01 13 0000 610 | Шәһәр җирлекләре бюджетларының башка калган акча өлешләрен кимету |